**Тукай бәйрәме**

**Бурычлар:**

1. Балаларның Г.Тукай иҗаты буенча алган белемнәрен гомумиләштерү һәм сәхнәләштерү белән кызыксыну тәрбияләү.
2. Телнең сәнгатьлелеген камилләштерү, хәтер сәләтен үстерү.
3. Әкияттәге төп фикерне аңларга, әсәрне сәхнәләштерергә өйрәтүне дәвам итү.

**Җиһазлар:** музыкаль үзәк, проектор, ноутбук, әкиятләр буенча слайдлар. Уеннар өчен атрибутлар.

**Кулланылган әдәбият.**
К.Закирова "Иң матур сүз"
К.Закирова "Балачак-уйнап-көлеп үсәр чак"
К.Закирова "Үстерешле уеннар"

(Зал бәйрәмчә бизәлгән, уртада Г. Тукай портреты)

-Исәнмесез, хәерле көн, кадерле балалар, мөхтәрәм тамашачылар! Без бүген татар халкының йөзек кашы булган сөекле шагыйребез Габдулла Тукайның туган көнен билгеләп үтү кичәсенә җыелдык.

Туган ягыбызга сагынып көткән яз аяк басты. Карлар эреп бетеп, җылы яктан кошлар кайта, бар табигать җанлана, кышкы озын-озак йокысыннан уяна. Әйдәгез, язны сәламләп, яз килүенә чын күңелдән сөенеп "Яз җитә" җырын башкарыйк.

**Җыр "Яз җитә"**

Язның шундый матур көнендә - 26 апрель көнне җиһанга бөек шагыйребез Г.Тукай туган.

**1 бала** ***Арина***
Апрель җитсә, исемеңне
Җырына куша тургай.
Милләтемнең кояшы син,
И моңлы, нурлы Тукай !

**2 бала** ***Ш.Әмир***
Илдә кояш, җирдә кояш,
Тукай көне канат җәйгән.
Бәйрәм бүген, бәйрәм бүген,
Тукай көне – безнең бәйрәм!

**3 бала** ***Зәмирә***
Иң матур, моңлы җырларны
Халыкка бирде Тукай.
Моңнары белән мәңгегә
Йөрәккә керде Тукай.

**4 бала.** ***Айзилә***

Хикмәтле шигырьләреңне
Укыйбыз кабат-кабат.
Балачак хыялларына
Бирәләр алар канат.

**Тәрбияче.**
Бәйрәмнәрең алда икән әле
Кара, шагыйрь, бүген текәлеп
Халкың килде, сиңа мәхәббәтен
Ал чәчәкләр белән белдереп. *(Балалар чәчәкләр куялар)*

**5 бала** ***Данис***
Әле укый белмәсәк тә,
“Туган телне” җырлыйбыз.
Бу-Тукай абый бүләге
Иң гүзәл бер җыр дибез.

**Тәрбияче .**
Син күрмәгән яңа буын килде,
Котлап бүген туган көнеңне
Киләчәккә барган улларыңнан
Ишетәсең “Туган телеңне”

**Җыр “Туган тел”**

**Тәрбияче .**

-Г.Тукайның балачагы бик авыр була. 5 кенә айлык чагында әтисе, 3 яшьлек вакытында әнисе үлеп китә. Әни шәфкате татырга да өлгермәгән сабый җаны ниләр генә күрми. Кулдан - кулга, авылдан - авылга күчеп үтә аның балачагы. Дөнья аңа бик күп мәшәкатьләр, авырлыклар бирсә дә, аның авылына, кешеләргә, теленә хөрмәте зур булып кала.

Балалар, Г.Тукай сезне бик яраткан, ул сезгә күп шигырьләр, әкиятләр, җырлар язып калдырган. Сез Тукай әсәрләрен беләсезме икән, хәзер күрәбез. Игътибар белән карагыз әле экранга, анда Тукай әсәрләренә иллюстрацияләр бирелгән.

**Уен “Кайсы әкияттән?”** *(Экрангда Г.Тукай әсәрләренә ясалган рәсемнәр чыга, балалар әсәрнең исемен атыйлар)*

*(Аркаларына капчык асып, Кәҗә белән Сарык керәләр)*

**Кәҗә** ***Кәрим***

Килдек сезгә кунакка
“Миләшкәй” бакчасына
Тукай китапларын алдык
Сарыкның акчасына.

**Сарык.** ***Т.Ислам***

Минем сезгә бер табышмагым бар.
Нәкъ кеше төсле үзе,
Һәркемне шаккаттыра.
-Былтыр кысты! – дип кычкыра
Туганнарын чакыра. Кем ул?

**Кәҗә.**

Мин дә әйтәм тыңлагыз:
Туннарга киендерә,
Җылыта сөендерә,
Тоягы анық ярык,
Исеме анық (сарык)

**Сарык:**

Тоягым ярык булса да,
Серле ул, сизәрсез сез.
Бергәләшеп уйныйк әле
Җиңәрсезме икән сез.

**Уен “Өлешләрдән җый”** *(Балалар ике төркемгә бүленеп “Су анасы” һәм “Шүрәле” әкиятләренә ясалган рәсемнәрне өлешләрдән җыялар)*

**Уен Татар халык уены “Түбәтәй”**

**Тәрбияче.**

-Кунаклар, сез утырып тыңлагыз әле, безнең балалар Тукай шигырьләрен өйрәнделәр. Сөйләп карасыннар әле.

**Кәҗә.** Минем капчыгым зур. Балалар шигырь сөйләгәндә мин аларны капчыгыма җыеп барырмын да, өемә кайткач нәни бәтиләремә сөйләрмен.

**Шигырьләр.** *(Балалар шигырьләр сөйлиләр)*

1. **Азалия "Карлыгач"**
2. **Семенова Ләйлә "Кошларга"**
3. **Илсаф һәм Самат "Кызыклы шәкерт"**
4. **Данис "Гали белән Кәҗә"**

**Тәрбияче.** Кәҗә белән Сарык, сезгә безнең балалар ошадымы?

**Кәҗә белән Сарык.** Әйе, бик ошадыгыз. Рәхмәт сезгә! Безгә китәргә вакыт. Сау булыгыз!

**Тәрбияче.** Габдулла Тукайның балачагы бик авыр булган дибез. Ләкин ул шуңа да карамастан, ул уйнарга, җырларга яраткан. Безнең балалар да җырлы-биюле уеннарны бик яраталар. Әйдәгез, бергәләп түгәрәккә басып, "Кәрия-Зәкәрия" җырлы-биюле уенын уйныйбыз.

**Җырлы - биюле уен "Кәрия-Зәкәрия"**

**1 бала.** ***Камил***
Әле укый белмәсәк тә,
"Туган телне" җырлыйбыз.
Бу-Тукай абый бүләге
Иң гүзәл бер җыр дибез.

**2 бала.** ***Ислам***
Әкиятләрен сөйләп, тыңлап,
Телләребез ачыла.
"Су анасы", "Шүрәлеләр"
Безнең дуслар барысы да.

**Тәрбияче.**
-Тукта, чү, әнә ишетәсезме, ямьсез тавышлы әллә нәрсә кычкыра.
*(Бии-бии шүрәле чыга)*
-Әйдә, Шүрәле абзый, рәхим ит! Тукай кичәсендә син кадерле кунак бит. Без сиңа бәйрәмгә чакырып язу җибәргән идек, син аны алдыңмы?
**Шүрәле.**
-Алдым, алдым, йөгереп килеп тә җиттем.
**Шүрәле.**
-Балалар, минем сезнең белән уйнап аласым килә.

**Тәрбияче .**
-Шүрәле абзый, безнең балалар “Без, без, без идек” уенын яраталар. Әйдәгез, шуны уйныйбыз.
**Уен “Без, без, без идек”** (*Кем күлә-шуңа җәза).*
**Җыр “Шүрәле”**
(*Аудиоязмада **“Шүрәле” җыры** яңгырый. Балалар түгәрәктә. Шүрәле аларны кытыклап йөри).*

**Шүрәле.** Балалар, сез чыннан да Тукай әсәрләрен беләсезме икән. Хәзер тикшереп карыйм.

**Уен “Кайсы әсәрдән?”** *(Шүрәле капчыгыннан тарак, балта, бүре башы, күбәләк чыгара)*

-Бу Г.Тукайның кайсы әсәреннән?

**Шүрәле.** Балалар, ә сез минем су буенда бакалар санап утыручы дустымны күрмәдегезме? Кем әле ул?

**Балалар:**

-Су анасы

**Тәрбияче.** Менә ул, Шүрәле абзый, синең дустың. Әйдәгез, Су анасы белән бер уйнап алыйк әле.

**Уен “Су анасы”**

*(Балалар түгәрәктә җырлап йөриләр.)*

*Су анасы, су анасы,*
*Су анасын күр әле.*
*Каршыңда кем басып тора-*
*Ялгышмыйча әйт әле.*
*(Су анасы каршындагы баланы капшап кем икәнлеген әйтергә тиеш)*
**Шүрәле.** Сезнең белән бик күңелле булды. Ләкин миңа китәргә вакыт. Сау булыгыз.
**Тәрбияче.**
-Балалар, сез Тукай әсәрләрен беләсез икән. Димәк, сез – аның оныклары. Киләчәктә дә бөек Тукаебызны онытмыйча, туган илебезнең бөек уллары һәм кызлары булып үсегез. Туган телегезне онытмагыз, аны саклагыз!